**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«02» 11 2022 ел № 3338

**Хисап чорына «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән ярдәмче күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында**

«2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген бәяләү хакында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Хисап чорына «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән ярдәмче күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын расларга.
2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022
елның «02» 11 3338
номерлы карарына 1 нче
кушымта

**Тукай районы буенча «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты»Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү федераль күрсәткеченең ярдәмче күрсәткечләрен җыю һәм мониторинглау регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты»Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү федераль күрсәткеченең ярдәмче күрсәткечләрен җыю һәм мониторинглау регламенты Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 04 февралендәге 68 номерлы Указы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикаларын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасының «Контроль» модуле эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде һәм «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керүче, муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән

«Әйләнә-тирә мохит сыйфаты»Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү федераль күрсәткеченең ярдәмче күрсәткечләрен (алга таба – ярдәмче күрсәткечләр) җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели.

Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларын уздыруның координаторы булып Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тора. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты/шәһәр округы урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чаралары буенча билгеләнгән тәртиптә оештыру чараларын һәм катнашучыларның иминлеген тәэмин итә.

Тукай муниципаль районында ярдәмче күрсәткеч зурлыкларын мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

Тукай муниципаль районында ярдәмче күрсәткеч зурлыкларын җыю өчен җаваплылык үзәге булып Тукай муниципаль районы чикләрендә урнашкан «Урманчылык» ДКУ (алга таба – «Урманчылык» ДКУ) тора.

Ярдәмче күрсәткеч зурлыклары турында мәгълүматны табигатьне саклау чараларында катнашучы юридик һәм физик затлар бирә. Ярдәмче күрсәткеч зурлыклары турында мәгълүмат бирү формасы Регламент кушымтасына туры килергә тиеш. Алына һәм тапшырыла торган мәгълүмат «Урманчылык» ДКУ җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән җаваплы зат тарафыннан архивлана.

«Урманчылык» ДКУнең муниципаль район/шәһәр округы буенча берләштерелгән мәгълүматы кәгазь күчермәдә яки электрон рәвештә Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты берләштерелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) электрон документ әйләнеше мәгълүмат системасын кулланып җибәрә.

## II. Төшенчәләр аппараты

Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла:

- Урманнарны торгызу – урман фонды территориясендә яңа урман утыртмаларын булдыру һәм формалаштыру чаралары.
- Урман үрчетү – электән урман утыртмалары булмаган җирләрдә яңа урман үсентеләре утырту чарасы.
- Урманны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык – агач утыртуда һәм башка табигатьне саклау акцияләрендә катнашучы физик затлар һәм/яки юридик затлар.
- Инициатив мәгълүмат – урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларында катнашучы яки катнашуны планлаштырган инициатив төркем тарафыннан бирелгән мәгълүмат.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чаралары үткәрелергә мөмкин:

- алдан әзерләнгән план буенча урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларын оешкан рәвештә үткәрү яки югары хакимият органнары һәм/яисә оешмаларны гамәлгә куючылар, коммерция оешмалары идарәсе органнары кабул иткән карарлар нигезендә оператив тәртиптә;

- иҗтимагый оешмалар, социаль учреждениеләр, җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, торак пунктларда яшәүчеләрнең инициатив төркемнәре, предприятиеләр һәм оешмалар тарафыннан алып барыла торган инициатив тәртиптә.

Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларының беренче категориясе урман фонды территориясендә үткәрелә. Кагыйдә буларак, бу – урманчылар билгеләгән урыннарда агач утырту чаралары. Урманны торгызу һәм үрчетү чараларын үткәрү планы (алга таба – План) Министрлык тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы белән килештерелә. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты урманны торгызу һәм үрчетү буенча планга туры килә торган чаралар графигын төзи һәм чараларда катнашучыларны әлеге график нигезендә чакыра.

Чараларның икенче категориясе – Тукай муниципаль районы территориясендә үткәрелә торган урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чаралары. Мондый чараларны мониторинглау формаль түгел, ә алар колачлаган халык саны шактый булганлыктан, санап үтелгән субъектларга мөлкәт, мәгълүмат, кадрлар, финанс формалары рәвешендә дәүләт һәм/яки муниципаль ярдәм күрсәтү чаралары каралырга мөмкин. Мондый чаралар исемлеге республика яисә муниципаль дәрәҗәдәге хакимиятнең тиешле органы тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта җирле дәрәҗәдәге чаралар яисә Тукай муниципаль районы бюджетында, яисә муниципаль дәрәҗәдәге программаларда һәм проектларда каралган чаралар составында карала.

Шулай итеп, чараларның беренче категориясе буенча мәгълүмат билгеләнгән чор өчен кушымта нигезендә хисап формасы буенча тапшырыла. Икенче категориядәге чаралар буенча мәгълүмат 1 кушымта нигезендә форма буенча чара үткәрүгә рөхсәт алганда тапшырыла, чараны үткәргәннән соң, мәгълүмат шул ук форма буенча килә, әмма инде хисап буларак.

Мәгълүмат җаваплылык үзәгенә – Тукай муниципаль районы территориясендәге «Урманчылык» дәүләт казна учреждениесенә электрон рәвештә яки кәгазь күчермәдә тапшырыла. Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты 1 кушымта формасы буенча исәпкә алу журналын алып бара. Кәгазь күчермәдән һәм электрон

рәвештә кергән формалардан мәгълүмат электрон документ әйләнеше мәгълүмат системасы ярдәмендә мәгълүматлар базасына кертелә, электрон документ әйләнеше мәгълүмат системасын кулланып Министрлыкка тапшырыла һәм 5 ел дәвамында исәпкә алу муниципаль электрон журналында саклана.

Кушымта

**Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны буенча мәгълүматларны мониторинглау формасы**

| План | | | | | | | | | Факт | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № | Чарада катнашучы (оешма/ физик зат) | Урман-чылык | Адрес | Чараны үткәрү датасы | Мәйдан, га | Утыр-тылган агачлар саны, мең данә | Төре | Катна-шучы-лар саны | № | Чарада катнашучы (оешма/ физик зат) | Урман-чылык | Адрес | Чараны үткәрү датасы | Мәйдан, га | Утыр-тылган агачлар саны, мең данә | Төре | Катна-шучы-лар саны |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |

*Искәрмә:* Министрлык адресына тапшырыла торган мәгълүматларның эчтәлеге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикаларын раслау һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары нигезендә билгеләнә.